**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе сәбәпле **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет төзү турында» 2013 елның 30 гыйнварындагы ПУ-71 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1098 номерлы, 2016 елның 7 маендагы ПУ-405 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге ПУ-310 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-308 номерлы, 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы һәм 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Д.Р. Ачылованы, Р.И. Вәлиевны, В.Н. Демидовны, В.И. Носовны, А.А. Фоминны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Габдрахманов Данияр Мәүлеяр улын – Болгар ислам академиясе ректорын (килешү буенча);

Александровская Ирина Алексеевнаны – «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча);

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Джураев Нусратилло Негматовичны – Казан шәһәре Чит ил студентлары һәм аспирантлары ассоциациясе президентын (килешү буенча);

Кадыйров Тимур Рәфкать улын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча);

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Ю. Әминовның – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

И.И. Гыйльметдиновның – «Татарларның федераль милли-мәдәни мохтарияте советы рәисе, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Милләтара мөнәсәбәтләр советы әгъзасы, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре буенча комитеты рәисенең беренче урынбасары (килешү буенча)»;

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Т.В. Забегинаның – «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча)»;

Р.З. Закировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

А.Р. Зариповның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча)»;

В.Е. Козловның – «Педагогика, психология һәм социаль мәсьәләләр институты директоры (килешү буенча)»;

Р.М. Мөхәммәтшинның – «Россия ислам институты ректоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 17 апрель
№ ПУ-236